**Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада сорауларына җаваплар (муниципаль тур, 2025-2026 уку елы) 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 43**

## I. Тест биремнәре (18 балл).

1. Халык авыз иҗатында эпик характердагы жанр, гадәттә әкият сюжетларын, риваять-легендаларны әдәби эшкәртеп язылган романтик эчтәлекле әсәр (2 балл):

Җавап: **дастан**

2. Әдәби әсәрдә пейзажның функциясе (1 балл):
1) әсәрне эстетик яктан бизи
**2) геройның эчке халәтен ачарга ярдәм итә**
3) әсәрнең тел-стилен камилләштерә

3. «Таһир белән Зөһрә» әсәре дастаннарның кайсы төренә карый? (2 балл):

Җавап: **мәхәббәт дастаны**

4. Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен тасвирлау (2 балл):

Җавап: **портрет**

5. Тышкы кыяфәт аркылы эчке халәтне бирү (2 балл):

Җавап: **психологик портрет**

6. Әдәби әсәрдә кешене чолгап алган әйберләр (2 балл):

Җавап: **әйберләр дөньясы**

7. Әдәби әсәрдә портретның функциясе (1 балл):
1) йөз матурлыгын ачып бирә
2) геройның эчке дөньясындагы уйларның тәртипсез хәрәкәтен күрсәтә
**3) укучының герой турында күзаллавын тудыруда ярдәм итә**

8. «Идегәй» әсәренең жанр формасы (2 балл):

Җавап: **тарихи дастан**

9. Нурихан Фәттахның «Итил суы ака торур» романында төп символик образ (2 балл):

Җавап: **<u>Идел елгасы, Идел суы</u>**

10. *Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның…* Әлеге өзек кайсы авторның нинди әсәреннән алынган? (2 балл):

Җавап: **<u>Әмирхан Еники «Әйтелмәгән васыять»</u>**

## II. Язма җавапка бәйле биремнәр (25 балл).

1. Теоретик төшенчә буларак конфликт. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда эчке һәм геройлар арасындагы тышкы конфликтларны табып языгыз (10 балл).

*<u>Конфликт – вакыйга-күренешләр нигезенә салынган характерлар һәм хәлләр, геройларның эш-гамәлләренең, карашларының һәм тормыш принципларының каршылыкка керүе. Ул геройлар арасында, кеше һәм тирәлек, кеше һәм яшәү рәвеше арасында, яки геройның үз эчендә булырга мөмкин.</u>*

*<u>Төп тышкы конфликтлар:</u>*
*<u>Айдар – Вәсилә</u>*
*<u>Айдар – Госман</u>*
*<u>Госман – Вәсилә</u>*
*<u>Төп эчке конфликт:</u>*
*<u>Айдарның күңелендә барган каршылык</u>*
*<u>Вәсилә күңелендә барган каршылык</u>*

2. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда йөзек кашы образының мәгънәсен ачыклагыз. Көчле позициягә чыгарылган әлеге образ әсәрдә нинди функция үти дип уйлыйсыз? (5 балл):

*<u>Йөзек кашы – әсәрдә мәхәббәт, беренче мәхәббәтнең, яшьлекнең сафлыгы символы. Госман йөзекне, үзенә сиздермичә генә, Вәсиләнең кулыннан салдырып ала. Ул аның йөзеген тартып кына алмый, аның яшьлек мәхәббәтенә, яшьлек сафлыгына кул суза.</u>*

3. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестендагы үзегез теләгән бер геройга характеристика бирегез (5 балл):

*Укучылар үзләре теләгән геройга характеристика бирергә тиешләр.*

4. Фатих Хөснинең «Йөзек кашы» повестенда автор фикерен – идеяне билгеләгез. Ул нинди проблемалар аркылы ачыла? (5 балл):

*Фатих Хөсни әлеге әсәрендә көнчелек, рухи әшәкелек, акыл белән эшләмәү, дуамаллык, эгоистлык, гаделсезлек, тугрылык һәм хыянәт һ.б. проблемалар күтәрә.*

*Әсәрнең төп идеясе: йөзек кашы булырдай мәхәббәтне саклау, бәхетле булу үзебездән тора, ашыгып карарлар кабул итмәскә кирәк, һәр кеше үзендә бәхетсезлекләрне ерып чыгарлык ихтыяр көче тәрбияләргә тиеш.*